**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Сөнчәле авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

05.11.2019 года № 90

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм
үткәрү тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Сөнчәле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне, кушымта нигезендә, расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

авыл җирлеге Советының 2018 елның 02 ендә кабул ителгән 69 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында»гы Нигезләмәне раслау турында» гы карары ;

- Сөнчәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 .06 85 номерлы «Сөнчәле авыл җирлеге Советы 2018 елның 02.10. 69 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карары.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
5. Үтәлешне тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет Рәисе,

Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы: ___________________Крайнова И.В.